КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2018 ел, 19 декабрь г.Казань № 1179

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы; 2015 ел, 26 август, 623 нче; 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы; 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче; 2017 ел, 10 май, 269 нчы; 2018 ел, 30 июль, 613 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатлар һәм бурычлар өстенлекләрен тәэмин итә.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.16$^{1}$ һәм 3.3.54 пунктлар өстәргә:

«3.3.16$^{1}$. Сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшырганда биомедицина күзәнәк продуктлары белән эш итү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру.»;

«3.3.54. Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүне һәм социаль

юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү.»;

4.2 пунктның өченче абзацында «хезмәтнең имин шартларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин